Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Татарстан Республикасы

**КАРАР № 25**

Зур Мәшләк авылы 16 ноября 2018 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Зур Мәшләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында нигезләмәне һәм гражданнарның үзара салым акчаларын куллану тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясы, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 60 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Зур Мәшләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11, 81 статьялары белән Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Зур Мәшләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларын куллану тәртибе турында өстәмә нигезләмәне расларга.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында нигезләмәне һәм гражданнарның үзсалым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибен раслау турында»2016 елның 25 маендагы 11 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы,М.Горький урамы,50А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

“Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы М.Г.Заһидуллин